КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 24 март г.Казань № 266

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 15 август, 388 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 15 август, 388 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 20 сентябрь, 492 нче; 2007 ел, 29 декабрь, 788 нче; 2008 ел, 17 ноябрь, 818 нче; 2009 ел, 22 июнь, 418 нче; 2010 ел, 1 апрель, 217 нче; 2010 ел, 6 декабрь, 1003 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1041 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 13 декабрь, 1013 нче; 2012 ел, 2 июль, 576 нчы; 2012 ел, 17 сентябрь, 774 нче; 2013 ел, 22 май, 341 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 799 нчы; 2013 ел, 19 ноябрь, 896 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 253 нче; 2014 ел, 31 май, 372 нче; 2014 ел, 16 сентябрь, 665 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 12 декабрь, 983 нче; 2015 ел, 11 июнь, 433 нче; 2015 ел, 17 сентябрь, 684 нче; 2015 ел, 14 октябрь, 767 нче; 2015 ел, 22 декабрь, 984 нче; 2016 ел, 31 март, 186 нчы; 2016 ел, 22 июль, 501 нче; 2017 ел, 8 май, 266 нчы; 2017 ел, 13 июнь, 375 нче; 2017 ел, 19 июнь, 390 нчы; 2017 ел, 31 август, 623 нче; 2017 ел, 26 сентябрь, 720 нче; 2018 ел, 15 февраль, 89 нчы; 2018 ел, 11 июнь, 448 нче; 2018 ел, 20 август, 675 нче; 2018 ел, 9 октябрь, 915 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2018 ел, 17 декабрь, 1154 нче; 2018 ел,

29 декабрь, 1322 нче; 2019 ел, 27 февраль, 134 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 769 нчы; 2020 ел, 21 февраль, 127 нче; 2020 ел, 26 март, 219 нчы; 2020 ел, 22 апрель, 317 нче; 2020 ел, 12 июнь, 487 нче; 2020 ел, 29 июль, 634 нче; 2020 ел, 29 август, 757 нче; 2020 ел, 2 октябрь, 903 нче; 2021 ел, 6 апрель, 217 нче; 2021 ел, 5 октябрь, 950 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1376 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.11. Законнар нигезендә социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә карата мәҗбүри таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәүне бәяләү, мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр, мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирү, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының $9^{13}$ статьясында (инвалидлар өчен социаль хезмәт күрсәтү объектларыннан һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәүдән тайпылу өлешендә) каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү, эшләрне карау, шулай ук Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.42, $13.11^{1}$ статьяларында, 11.24 статьясында (халыкка автомобиль транспорты белән транспорт хезмәте күрсәтү системасын (җиңел таксидан тыш) оештыруга һәм муниципальара элемтәдә автомобиль транспорт чараларын эксплуатацияләүгә җаваплы оешма җитәкчесе яки башка вазыйфаи заты тарафыннан инвалидлар файдалана алган транспорт чараларын халыкка транспорт хезмәте күрсәтү системасына кертүне күздә тоткан законнар таләпләрен бозу өлешендә) каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү гамәлгә ашыра.»;

түбәндәге эчтәлекле $3.3.11^{1}$ пункт өстәргә:

«$3.3.11^{1}$. Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының $20.6^{1}$ статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүне башкара.».

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карарның 1 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацлары гамәле 2022 елның 31 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

бу карарның 1 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацлары 2022 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) гамәлдә була.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин